СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

04.07.2022 с. Верхний Услон 24-319

Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының 2015 елның 24 апрелендәге 57-557 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс - бюджет Палатасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Тулы исеме: Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы» муниципаль казна учреждениесе.

Кыскартылган исеме: Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы»;

1.2. 5 бүлекнең 5.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.1.Палатаны Палата эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Палата рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнеп куела. Палата рәисе вазыйфасына кандидатның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән тикшерүне уздыруда Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә».

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс - бюджет Палатасы турындагы Нигезләмәнең текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин

Югары Ослан муниципаль районы
Советының 2022 елның 4 июленнән
24-319 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Финанс-бюджет Палатасы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Югары Ослан муниципаль районының Финанс - бюджет Палатасы (алга таба Палата) - җирле бюджетка хезмәт күрсәтү һәм җирле бюджет акчалары белән идарә итү максатларында булдырылган Югары Ослан муниципаль районының (алга таба Район) финанс органы.

Палата Район Советы тарафыннан муниципаль казна учреждениесе формасында төзелә.

Палатаның юридик зат хокуклары белән бирелгән үз исеме, штамплары һәм билгеләнгән үрнәктәге бланклары белән мөһере бар.

Палатаның төп бурычы - район бюджетын төзү һәм үтәү, шулай ук аның үтәлеше турында отчет.

Тулы исеме: «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы» муниципаль казна учреждениесе.

Кыскартылган исеме: Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы

1.2. Палата үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга, Район Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

2. Палатаның бурычлары

2.1.Палатаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1.1. Район территориясендә бердәм финанс, бюджет һәм салым сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2.1.2. Җирле бюджет проектын төзү һәм аны билгеләнгән тәртиптә үтәүне тәэмин итү;

2.1.3. Районның җирле бюджеты һәм берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында хисап төзү;

2.1.4. Муниципаль алынмалар программаларын эшләү һәм аларны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру;

2.1.5. Федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү.

3. Палата функцияләре

3.1. Палата үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне үти:

3.1.1.бюджетара мөнәсәбәтләрне камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм чараларын гамәлгә ашыра;

3.1.2. Район территориясенең социаль-икътисадый үсеш фаразларын эшләүдә билгеләнгән тәртиптә катнаша;

3.1.3. эре салым түләүчеләрнең салым түләүләренә мониторинг үткәрә;

3.1.4. Муниципаль максатчан программаларны әзерләүдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә аларны җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслауны тәэмин итә;

3.1.5. бюджет һәм башка муниципаль хокукый актлар турында Район Советы карарлары проектларын эшләүдә билгеләнгән тәртиптә катнаша;

3.1.6. үз компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар эшли һәм аларны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгара;

3.1.7. җирле бюджет проектын төзи һәм аны Районның Башкарма комитетына тапшыра;

3.1.8. Районның берләштерелгән бюджеты фаразын эшли;

3.1.9. Үз компетенциясе чикләрендә җирле бюджет үти, җирле бюджетның һәм районның берләштерелгән бюджетының үтәлеше турында хисап төзи;

3.1.10. Районның Башкарма комитетына җирле бюджетның үтәлеше турында хисап бирә;

3.1.11. җирле бюджетның бюджет язмасын төзи;

3.1.12. эчке финанс контролен гамәлгә ашыра, сатып алулар өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыра;

3.1.13. җирле үзидарә органнары структурасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша; Районның җирле үзидарә органнары аппаратларын тотуга ассигнованиеләрнең иң чик саны һәм күләме турында тәкъдимнәр әзерли, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша;

3.1.14. бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерли;

3.1.15 салым сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнаша;

3.1.16. җирле үзидарә органнарының җирле салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актларын куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

3.1.17. эмиссия һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру өлкәсендәге сәясәтне гамәлгә ашыра;

3.1.18. муниципаль алынмалар структурасын формалаштыру өлкәсендә бердәм сәясәт эшли һәм гамәлгә ашыра;

3.1.19. Район Башкарма комитеты җитәкчесе йөкләмәсе буенча район исеменнән чираттагы финанс елына район бюджеты турында район Советы карары белән билгеләнгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме чикләрендә муниципаль гарантияләр бирә;

3.1.20. билгеләнгән тәртиптә муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең эмитенты сыйфатында чыгыш ясый, муниципаль займнарны чыгару һәм урнаштыру шартларын эшли;

3.1.21 муниципаль бурыч кенәгәсен алып бара;

3.1.22. муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

3.1.23. чираттагы финанс елына бюджет турында Район Советы карары белән расланган чаралар лимиты чикләрендә һәм Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бюджет кредитлары бирүне тәэмин итә;

3.1.24 муниципаль эчке бурыч структурасын камилләштерү һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнарын оптимальләштерү буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашыра;

3.1.25. максатчан бюджет фондлары акчаларын формалаштыру һәм куллану буенча тәкъдимнәр әзерли;

3.1.26. бюджет акчаларын алучыларның, шул исәптән бюджет кредитлары һәм муниципаль гарантияләр алучыларның, бүлеп бирү, алу, максатчан файдалану һәм бюджет акчаларын кире кайтару шартларын тикшереп тора;

3.1.27. җирле бюджет акчаларын баш бүлүченең һәм алучының функцияләрен гамәлгә ашыра;

3.1.28 гамәлдәге законнарда каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

## 4. Палата хокуклары

4.1. Палата хокуклы:

4.1.1.билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр өчен кирәкле материалларны соратырга һәм алырга:

- җирле бюджет проектын эшләү;
- Районның берләштерелгән бюджеты фаразын исәпләү;
- җирле бюджетның үтәлеше турында хисап төзү;
- Районның берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында хисап төзү.

4.1.2. максатчан бюджет фондлары буенча билгеләнгән тәртиптә материаллар соратырга һәм алырга;

4.1.3. Палата компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә кирәкле белешмәләрне соратырга һәм алырга;

4.1.4. закон нигезендә бюджет законнарын бозучыларга карата мәҗбүр итү чараларын кулланырга;

4.1.5. салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә салымнар һәм җыемнар түләү срокларын үзгәртү турындагы карарны килештерергә.

## 5. Палата эшен оештыру

5.1.Палатаны Палата эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Палата рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча билгеләнеп куела. Палата рәисе вазыйфасына кандидатның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән тикшерүне уздыруда Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Палата рәисенә Югары Ослан районы Башлыгы күрсәтмәсе нигезендә ел саен төп һәм өстәмә отпуск бирелә.

5.2. Палата рәисе урынбасары муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча үз вазыйфасына билгеләнә.

5.3. Палата председателе:

- бердәмлек нигезендә Палата эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- Палата хезмәткәрләре арасындагы бурычларны бүлә;
- билгеләнгән тәртиптә районның Башкарма комитетына Палата компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар проектларын кертә;

- үз вазыйфасына билгеләнгән тәртиптә Палата хезмәткәрләрен билгеләп куя һәм вазыйфасыннан азат итә;
- законнар, Район уставы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5.4. Палата аппаратын тоту чыгымнарын финанслау җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин